**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ИСЕНБАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСӘНБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

28.07.2023 Исәнбай авылы № 32

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы "Исәнбай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә этләрне йөртү һәм (яки) өйрәтү өчен билгеләнгән урыннарны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советының 15.09.2018 елның 43-1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының "Исәнбай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 2.12.16.2 пункты, «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2023 елның 15 маендагы 02-06-2023/Прдп 196 номерлы күрсәтмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге территориясендә этләрне йөртү һәм (яки) өйрәтү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1) Исәнбай авылының көньяк өлеше Совет урамыннан 50 м ераклыкта.

2. Этләрне йөрткәндә һәм (яки) өйрәткәндә түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк:

1) Автомобиль юлының йөрү өлеше киселгәндә, күпфатирлы йортларның гомуми файдаланудагы биналарында, мондый йортларның ишегалларында, балалар һәм спорт мәйданчыкларында хайванның ирекле, контрольсез йөрү мөмкинлеген юкка чыгарырга;

2) хайваннарның тормыш эшчәнлеге продуктларын гомуми файдаланудагы урыннарда һәм территорияләрдә җыештыруны тәэмин итәргә;

3) Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлеге Башкарма комитетының әлеге карары белән рөхсәт ителгән урыннардан читтә хайванның йөрүенә юл куймаска

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Исәнбай авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Ф.Ф.Сираев